| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | 22.11.2023<br>1866 | КАРАР |

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (3 нче кушымта);

-Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне (4 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы, бу чорда хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычларының күләме һәм аларның шул ук квалификация эшләрен башкару шарты белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытта гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан ким була алмый, дип билгеләргә.

**3.** Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле һөнәр ияләре берлекләре органы белән килештереп:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

шартларын билгели торган күмәк шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 августындагы 1178 номерлы карары үз көчен югалткан дип таныргa.

5. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары итеп йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1866 от 22.11.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 30.11.2023 15:57

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 30.11.2023 - 19:47 | - |